УДК 82-94

***Гаяз Исхакый***

# ЯПОНИЯДӘН КИТЕП БАРЫШЛЫЙ

*(әдип көндәлегеннән)*

При содействии организатора фонда «Аяз Тахир (Туркестан – Идель-Урал)» доктора Тулей Дурана из Турции на историческую родину было возвращено богатое письменное наследие классика татарской литературы Гаяза Исхаки. Часть этого наследия в настоящее время хранится в ЦПиМН ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Среди этих материалов большое значение имеют электронные копии личных дневников писателя, которые он вел в период с 1919 по 1953 гг. Гаяз Исхаки в 1919 году, будучи делегатом Версальской конференции, выезжает через Дальний Восток в Европу, где и остается до конца своей жизни. В этих дневниках раскрыта тяжелая жизнь в эмиграции, выпавшая на долю Г. Исхаки.

**Ключевые слова:** Г. Исхаки, Г. Терегулов, Ф. Туктаров, Учредительное собрание, Япония, Китай.

*1919 ел, 1 нче июль.*

Бүген Солых бәйрәме. Бөтен урам автомобиль берлән тулган. Һәммәсе дә төрле-төрле иттифакъчыларның байраклары берлән зиннәтләнгәнләр. Японча-инглизчә шигарьләр язганлар, урам тулы халык. Һәммәсе солых булганга шадлыкларын белдермәкче булалар. Диңгездәге япон крейсеры бер туктамаенча ата. Ләкин рух алай ук түгел. Һәр кешенең йөзендә шул солыхга бер ышанмау чыкган. Барысының да йөзенә бар да йөрегәч, без дә йөримез дигән мөһер басылган. Без дә урамга тамаша карарга чыкганда, урамда бик күп чех солдаты очратамыз, сорашамыз. Владивостокдан икән. Анда, дүртенче эшелонда, безнең якын танышымыз, Учредительное собрание әгъзасы, комитетның мәгариф нәзары булып торган Егор Егорович Лазарев[1] булырга кирәк иде. Чехлардан бармы, дип сорыймыз. Бар, дип җавап бирәләр. Кызулатып пристаньгә китәмез. Әллә никадәр чехдан сорашамыз. Кайсы бар, ди, кайсы юк, ди. Берсендән чакыртырга җибәрәмез, ләкин, юк, чыгып киткән, диләр. Без Йокоһаманың урамы буе эзләп таба алмагач, сәгать өчкә килермез дип, хат биреп китәмез. Безнең аны күрәсемез килүнең мәгънәсе бар. Чөнки алар бара торган пароход Америкага бара. Әгәр безне дә алса, мәсьәлә хәл ителгән була. Егор Егорович Харбинда вакытда безгә шулай барырга тәкъдим дә иткәнлеге, без ул вакытда үземезнең кәгазьләремезгә ышанып, бик соңга калачак дип, кабул итмәгән идек. Хәзер аны очрата алсак, бик кабул итү ягында. Сәгать өчдә тагын барамыз, җидегә

[1] Лазарев Е.Е. (1855–1937, тәхәллүсе – Бровинский,) – революционер, эсер, Учредительный собраниегә делегат итеп сайланган.

кадәр көтәмез. Һаман юк да юк. Ахырдан аның анда булмавы, пароходда комитетның икенче әгъзасы Брушвитның[1] гына булуы мәгълүм була. Аны күрергә тырышамыз. Ул да тугры килми. Иртә күрергә булып китәмез. Кичкә безгә Иван, Вафа һәм дә Окубо[2] күрешергә киләләр.

Бүген рамазан бәйрәменең өченче көне булса да, без бер әрмән, бер япон, бер төрек компаниясендә бәйрәм итәмез. Өченче көнгә иртәнге поездга билет алырга куштык. Бүген кичке телеграммада кытайларның сольх могаһәдәсенә *(килешүенә)* кул куймаулары мәгълүм булды. Кытайның Токиодагы сәфире Токио шәһәр башлыгы тарафыннан бирелгән зыяфәткә дә килмәгән. Кытай – истикъляли *(бәйсез)* милләт. Киләчәкдә шәрыкдә зур роль уйнаячак.

*2 нче июль.*

Бүген озак йөрегәндән соң, Гомәр[3] чехлар пароходындагы кешеләрне күреп кайтды. Болар берсе Брушвит, икенчесе Климушкин[4] икән. Болар – Учредительное собрание комитетында зур роль уйнаган затлар. Хәзер чех булып, солдат киемендә, солдат боткасын ашап, Америкага качып китеп баралар... Без иртәгә китә алмыймыз, чөнки билет булмады.

*3 нче июль.*

Бүген вак-төяк әйберләр алгалап үткәрдек. Иртәгегә билет алдык. Насыйп булса, китәмез. Бүген акча курсы төшде. Себер акчасын бөтенләй алмыйлар. Омскида тагы үзгәреш бар, диләр. Колчак[5] берлән Дутов[6] тартыша имеш. Ни булса да, Колчакның вәзгыяте бик начарлана булырга кирәк.

*4 нче июль.*

Бүген, иртүк торып, поездга китдек. Поездымыз 9 сәгать дә җиде минутда Йокоһама стансасыннан китде. Бик кызу бара. Болай барганда, иртәгә иртәнге пароходка барып җитәчәк. Көн бик бөркү, шуның өстенә, бик ягмурлы. Монда әллә нинди үзенә махсус йылы, вак ягмур ява. Болыт шулкадәр түбән, кул сузсаң, җитәчәк. Поезд тау буйлап барганда, тауның итәгенә китә торган башына менеп җитмәгән бик күп болыт агымларына очрыймыз. Бер йирдә, тау өстенәрәк менгәч, поездымыз ярты сәгать чамасы болыт эчендә бара. Көн шулкадәр бөркү, вагонда суга батып барамыз. Кичкә таба сәгать җиделәрдә безгә японча әллә нәрсә килеп сөйлиләр, ләкин без аңламыймыз. Бераздан безгә бер инглиз: «Поезд бара алмый, юлны ягмур юган, шуның өчен, теләсәгез, Кобеда каласыз,

---

[1] Брушвит И.М. (1879–1946) – эсер, Учредительный собрание әгъзасы.
[2] Окубо Кочи – Комазава университеты профессоры, тюрколог.
[3] Гомәр Терегулов (1883–1938) – сәяси эшлекле, педагог.
[4] Климушкин П.Д. (1886–1969) – эсер, Учредительный собрание әгъзасы.
[5] Колчак – Александр Васильевич Колчак (1874–1920), патша Россиясе хәрби эшлеклесе.
[6] Дутов – Александр Ильич Дутов (1864–1921) – атаман, генерал-лейтенант.

теләсәгез, андан ике сәгатьлек йирдә Окаямага да туктыйсыз. Әүвәлгесе зур шәһәр булганга, номерлар-отельләр күп, икенчесе япон шәһәре генә, Яурупада отельләр юк», – ди. Без, төрлетөрле уйлагандан соң, Окаямага барырга буламыз. Кызу, ягмур астында сәгать төнге 12 ярымда Окаямага төшәмез. Вокзалда һичбер төрле русча белгән юк. Шалтыр-полтыр белгәнемез берлән инглизчә сөальләр бирәмез, аңарга японча җавап бирәләр. Ахырдан бер түрәгә бераз инглизчә сөйләп аңлатамыз. Юлымызны өч йирдән ягмур юган, поезд Симоносекига бара алмый, ләкин иртәгә таң берлән сәгать биш дә пароход Симоносекига китә, шулай булгач, без вокзалда гына көтәргә буламыз. Сәгать бишкә кадәр көтәмез, алтынчы була, тагы сорыймыз. Поезд сәгать унда китәчәк, пароход юк, диләр. Аңарга ышанмыйча, икенчесендән сорыймыз. Поезд сәгать дүртдә китәчәк, ди. Шундан соң, боларның сүзләренә өмет юклыгын күреп, тагын белешергә тырышамыз. Поездның кай вакыт китәчәге мәгълүм түгел, дип игълан иткән сүзне белгәч, номер эзләргә тотынамыз. Ерак түгел бер япон өе табып, шунда керәмез. Камыш намазлык, бүлмәнең идәненә урын салалар. Баш астымызга озынча йомры мендәрләр бирәләр. Пальтоларымыз берлән йокларга ятамыз. Сәгать унларда торып, тагы белешергә китәмез. Тагы кырык төрле хәбәр. Берсе кич сәгать җидедә китә, ди. Берсе сәгать унда, ди, сәгать унбердә, ди. Бер ресторанга кереп, чәй эчәргә утырамыз. Йомырка, күмәч, май, чәй сорыймыз. Элгәре май китерә. Андан чирек сәгатьдән йомырка китерә. Андан чирек сәгатьдән әллә нинди соры бер су китерә. Андан чирек сәгатьдән икмәк. Моңарга ачу килеп, йөдәп беткәч, үземез барып күрсәтеп, тагы белешергә китәмез. Анда беразрак русча белә торган япон офицерына очрыймыз. Ул юл бик нык бозылган, ягмур һич туктамый. Поезд өч-дүрт көнсез төшәчәк түгел, ди. Сәгать өч ярымда Кобега китәмез. Көн буе ягмур ява. Поездымыз бер туктамаенча су диңгезендән йөзә. Уң як, сул як су берлән капланган. Күкдән ягмур чиләкләп актарыла. Дөге кырлары су эчендә. Иң зур дөге саплары да күренми. Сәгать сигездә Кобега[1] киләмез. Билетсыз йөдәп бетеп, бер нәрсә эшли алмагач, бер япон номерына китәмез. Ашаганымыз-эчкәнемез юк. Өстемез башдан-аяк су, тир эчендә үземез. Чәй һәм йомырка китерергә кушамыз. Ике сәгатьдән соң йомырка, былчырак чәй эчеп ятып йоклыймыз.

*6 нчы июль.*

Бүген иртүк торып юынганның соңында пароход мәсьәләсенә керешәмез. Русча белә торган япон вәгъдәсенә килми. Аны бик тынычсызланып көткәннең соңында, ике сәгать кичегеп килә, пароход сәгать уникедә китә, ләкин икенче классда да, беренче классда да урын юк, фәкать өченчедә генә бар.

[1] Симоносеки, Кобе, Окаяма – Япониядәге шәһәрләр.

Дүртенчедә булса да ярый, ал гына. Бездән билет акчасы алалар, биш мәртәбә артык хак алганлар. Пароходка кереп утырамыз. Урынымыз иң аскы катда, трюмда. Анда биниһая эссе. Эчәргә сорыймыз, бирмиләр...

Менә кич. Ай моңлы гына яктысы берлән диңгезне сөя. Диңгезнең төбендәге яшерен хәятләрен, диңгезнең эчендәге серләрен укымакчы була. Пароход әйтеп бетермәслек муллыкны ертып, һаваланып, йокларга яткан диңгезне ерып алга таба бара...

Төнемезне капитандан камыш намазлыклар сорап алып, баш астымызга пальтоларны салып йокларга ятамыз. Ике якдагы ачык тәрәзәләрдән диңгез һавасы безне сөя-сөя йоклата. Әнә таң сызылып килә. Диңгезнең әнә теге очында зур куәтле бер кызыл нәрсә чыгарга теләп маташа.

Берничә карт япон чыкканлар да кояш чыгышка карап басканлар. Күзләре кояш чыгышына текәлгәнләр. [...] дип кычкыралар да, кулларын берсенә-берсен борып, шарт иткән тавыш чыгаралар, андан әллә нинди сүзләр мыгырдыйлар. Шул эш берничә мәртәбә кабатлана да, куллары берлән йөзләрен сыйпап, борылып китәләр. Болар кояшка гыйбадәт итәләр. Безнең элекке төрк бабайлар кояшка ничек гыйбадәт иткән булсалар, болар да шулай гыйбадәт итәләр.

Юынырга төшәм. Юыну бүлмәсе ир-хатын берлән шыгрым тулган. Хатынлар һәммәсе дә билләренә кадәр бөтенләй ачканлар, тәнләрен акшарлыйлар. Ирләре дә шулай. Берсе-берсенә карамыйлар да, илтифат да итми. Мин боларның шул гадәтләренә, шул безнең канга сеңгән «оят», «оят булу» дигән мәгънәнең булмавына гаҗәпкә калам. Мин күлмәкләрне салмаенча гына юынырга керәм...

Пароход өстенә чыгам... Мин диңгез авыруындан курыкмаганга, пароход өстендә калдым. Бик күп кеше. Безнең пароход бик кечкенә булганга, дулкын бик куәтле булганга, ул тирбәнә, кайвакыт бөтенләй дулкын астында кала кебек була. Дулкынлар пароход өстенә менеп, йөгереп төшәләр. Мин һаман бер почмакдарак коры калып барам. Менә бер дулкын икенчесен куып җитде, алар бер-берсен кочаклап, мине су башымдан аягыма кадәр коендырды. Астымдагы урындык шуып китде. Мин суга батып, бүлмәгә кереп, урынга ятдым, юрган ябындым.

Урынга бик вакытлы килеп төшәмез.

*8 нче июль.*

Бүген иртәдән бирле без Корея буйлап барамыз. Кыр тулган халык. Һәммәсе без үле күргән кебек ак киемдән. Кырда эшли торган ирләрнең барысы да билгә кадәр бөтенләй ялангач. Хатынлар тәмам ук ялангач булмаса да, күп йирләре ачылган. Балалары да япа-ялангач. Кырдагы эшнең хәзергесе дөге сугару, икенчесе аны утау һәм дә төбен йомшарту. Ирләр төрле ысулда кораллар берлән үзләренең җыйнаган чүпләрен дөге түтәлләре эченә куялар, хатынлар тездән су эчендә дөге утыйлар, төпләрен йомшарталар. Монда әле урып бетмәгән бодай берлән солы

очраштыргалый. Көн буе шул бер төрле эш. Мескенләр, тамак туйдырыр өчен бик зур мәшәкатьләргә күрергә мәҗбүрләр...

*10 нчы июль.*

Без кичә кич берлән Чанчуньга[1] килеп җитдек. Монда безне көтеп торалар икән. Безне чакырган мәсьәләләре бик кечкенә вакыйга, сәяси тәрбиясезлекдән килеп чыккан бернәрсә генә булды. Аны ни дип тә тәгъбир итәр хәл юк. Кыскасы, мондан гыйбарәт: Нияз әфәнде үз эше берлән барганда, аны Семенов[2] берлән күрешдергәнләр. Семенов безнең мөселман эшләре берлән бик танышасы килә һәм дә безнең берлән мөнәсәбәткә керешеп, мөмкин булса, бергә хәрәкәт итәсе килә икән. Себер мөселманлары, Кытай мөселманлары хакында бергәләшеп бер эш эшләп булмасмы, дип уйлый икән. Шуңарга күрә безне күреп сөйләшәсе килә икән. Шуның өчен Нияз әфәндегә безнең берлә барып сөйләшергә әйткән һәм дә юлына акча да биргән. Сөйли торгач, эшнең артында японлар да барлыгы мәгълүм була. Без мәсьәләне мөзакәрәгә куеп, карарлар ясыймыз: беренче, Семенов берлән мөзакәрәгә керешергә ярый. Милли сәясәтне йөрткәндә, ноктаи нәзар фәкать милләтнең мәнфәгате генә булырга кирәк. Шул милли мәнфәгать өчен тартышуда кем ярдәм итсә дә, шул ярый. Сөйләшәчәк мәсьәлә мондан гыйбарәт: Семеновның сәяси даирәсендә безгә бер шәһәр бирелсен, шунда без үземезгә махсус төрк-татар гаскәре төзик. Семенов шул хәрәкәтемездә безгә ярдәм итсен һәм дә безнең мөшкилятемез фәкать шул үземезнең милли эшемез өчен генә тотылсын. Шул мәсьәләләр хакында Семенов берлән фикер алышырга без разый. Шундан соң хәзер үк Семенов берлән барып сөйләшү кирәкме, бераз соңракмы мәсьәләсе куелды. Ул мәсьәлә безнең солых сәфәремезгә барып төртелә. Безнең солых сәфәремез алты ай дәвам иткәннең соңында Япониянең диңгезенә терәлде...

*11 нче июль.*

Минем Окаямада калган чемоданларым бүген килде. Эчендә бик күп әйбер бар һәм дә яңлыш куелып калган уналты мең сум акча да бар иде. Һәммәсе саусәламәт килделәр. Японлар бу хасиятләрне тәкьдир кылмаска мөмкин түгел. Көн буе теге мөзакәрәләр дәвам итде. Ахырдан Нияз әфәнде Кытай эченә барып кайтырга, Габдулла берлән хәзрәт китәргә дә безгә кеше эзләргә, безгә Чанчуньда көтеп торырга булдылар.

*13 нче июль.*

Бүген бер ни дә булмады. Кызулыкдан, тузандан йончып, өйдә ятдык. Монда тору бик мәгънәсез. Һавасы начар. Кешесе юк. Эш юк...

Гомумән, эш, җәмәгатьнең иштираке берлән булмаганда,

[1] Чанчунь – Кытайның Гирин провинциясендәге шәһәр.

[2] Семенов Григорий Михайлович (1890–1946) – атаман, генерал-лейтенант.

бер ни чыкмый. Кечкенә генә бер мисал. Инглиз матбугатына бирер өчен русчадан мәкаләне инглизчәгә тәрҗемә итдергән идек. Шуны карап мәкалә ясап чыгарга Габдулла Газиздән үтендек. Шул ике сәгатьлек эш эшләмәде. Инглизчә белә торган кешеләремез бер-ике данә булып, алары да шулай милли саботаж ясаганда,ничек эшләргә кирәк.

*14 нче июль.*

Бер ни юк. Бераз ягмур яуды да, һавалар матураеп китде. Бүген газета да юк. Кичәге хәбәргә караганда, большевиклар Екатеринбургка һөҗүм итәләр.

*15 нче июль.*

Бүген иртүк Әмрулладан[1] мәктүб алдык. Шимбә көн киләм дигән. Шуңарга күрә, аны шактый озак көтәргә тугры киләчәк. Монда һичбер эш юк. Безнең бу сәфәрнең ундан тугызы көтәргә китде. Хат көт, җавап көт, телеграмма көт, иптәшләрне көт. Монда бүген бик зур тантана берлән Гириндан[2] Кытайның зур бер түрәсе килде. Аны каршы алырга бөтен гаскәре җыелган. Вокзал башына гаскәре караул куелган иде. Арбасына утырып мәйданга чыгуга атлы гаскәр бик күп сыбызгыдан кычкырта башладылар. Зур тавыш кубды. Миңа кечкенә вакытымда яңа сыбызгылар тотып, дәүрәк малайлар берлән сабан туендан кайтканны хәтерләтде. Бу арада Гирин губернаторы берлән Мукден губернаторларының аралары ачылып тора. Икесе дә Маньчжуриягә генерал губернатор булырга тырышалар. Бу эшне хөкүмәтләре берлән аңлашып эшләп булмый күрәсең. Ике губернатор да берсе-берсе берлән сугышмыйча мәсьәләне хәл кылырга уйлаганлар. Гирин губернаторы Японияга бик күп йир саткан. Гомумән, Япония берлән эш итде, шуңарга күрә Кытай үзен яратмый, ди. Мукден губернаторын халык ярата, ди. Кыскасы гына, боларның берсе Кытайның истикьлялен саклау тарафында булып, Японияга дошман, берсе Япония берлән эш күрү тарафында булырга. Ике агым тартыша-тартыша сугышка барып җитәләр булырга кирәк. Гирин губернаторы җиңсә дә, Мукден губернаторы җиңсә дә, Япония шул сугышындан файдаланып, бармагын зуррраграк тыгачак, бәлки Маньчжуриянең аерым бер дәүләт булуына эш җиткерәчәк. Бакалым, ни булыр...

*16 июль.*

Бүген яңа бер эш дә юк. Мәктүб булмагач, кичә үзем язып җибәрдем. Бу мәгънәсез көтү бик туйдырды. Бүген хисапларны карадым, әле расход бик аз тотылган. Шул акчалар берлән бик һәйбәтләп йөреп кереп булчак да бит, расходымызның очы-кырые булмады. Андан соң һичбер ярдәмче юк. Гомәр салам селкетми. Паспорт булса, Харбинга барып, андан Владивостокга бару уенда торам.

---

[1] Әмрулла Аги – Харбинда мәхәллә җитәкчесе.

[2] Гирин – Кытай провинциясе.

*17 нче июль.*

Бүгеннең иң зур вакыйгасы – большевикларның Златоустны алулары булды. Димәк, большевик Уралның бу ягына чыкды. Хәзер Омскига хәрәкәт башлана.

Көн бик эссе, өйдә утырып булмый. Кырык градусдан артык. Милли идарәне эзләргә вә табып, җавап китерергә бер кеше җибәрергә булган идек, Омскидан Колчак кача башласа, милли идарәне табуы бик авыр булыр кебек күренә. Газеталарга караганда, Омскига чит кешене кертмиләр, димәк анда зур паника башланган.

*18 нче июль.*

Бүген милли идарәгә озын мәгърузә *(доклад)* яздым. Томскида Нурулла Карповка[1], Петропаулда Мостафа Тумашевка озын-озын хатлар берлән мәсьәләне тәмамән ачдым. Һәммәсендән дә берничә сөальләргә җаваплар сорадым. Бу мөрәҗәгать берничә мәртәбә булмаса да, бәлки берсендән-берсендән бер җавап килеп чыгар. Мәсьәлә, фәүкыльгадә, чуалчык дәвергә керде. Булмады дип эшне туктатсак, вөҗдан канәгатьләнми, дәвам итдерергә дип карар итсәк, ялгыз бер кеше һичбер бер ярдәмсез шул кадәр мөшкилят эчендә ни эшләмәкче буласың. Әгәр заграницага чыгып киткән бер-ике кешемез булса, әлбәттә, шуларга телеграмма, мәктүб берлән эшне аңлатып, алардан эшне дәвам итдерергә үтенер идек...

*19 нчы июль*

Бүген мобилизациягә баруның беренче көне. Монда Чанчуньда артык бер нәрсә булмады...

*20 нче июль*

Кичә кичдән яисә бүген иртә берлән Әмрулла әфәнде килергә тиеш иде. Мәктүбе дә, кеше артындан әйткән вәгъдәсе дә шулай иде, ни өчендер килмәде. Һәм дә сәбәпләрен күрсәтеп мәктүб дә булмады. Әллә мобилизация мәсьәләсе манигь булды, әллә башка эш. Инде аны тагы көтәргә кирәк. Безнең бу хәерсез сәфәремез көтүдән гыйбарәт булып чыкды. Бүген мин авырый башладым. Дөресе, авырыйм дип курыкдым. Тамакга бака калыкды, баш авыртды, ангина була дип шөбһәләндем. Башка эш бетде кебек инде, авырырга гына калды, ди. Бер туктамаенча тамак чайкап торып чыкдым. Кичкә таба бака бетде. Бүген газетада Екатеринбургны алу хәбәрен укыдык.

*21 нче июль.*

Бүген без көн буе Әмрулланы көтдек, ахрысы килми торгандыр. Хәерле булсын. Нияздан хәбәр алдык. Артык хәбәр юк.

*22 нче июль.*

Милли идарәдән мәктүб алдым. Мәктүб 12 нче июльдә генә язылган. Безнең күп мәсьәләләргә җавап биргән кебек – бик күп эшләрне томанда да калдыра. Беренче конференциядә сайланган

[1] Нурулла Карпов – Томскида «Том сүзе» газетасы нашире.

эш башы Фуад[1], Солтанбәк[2] әфәнделәрнең килүе мәгълүм түгел. Алар рәсми рөхсәт алырга дип тотынган булганлар да, шуны дәвам итдергәнләре юк, мәгълүм булмаган. Солтанбәк солдатка алынган. Фуады Омскида торадыр, ди. Икенче, безнең виза мәсьәләмез хакында. Анда зур чуалулар чыкган...

Гомәр хакында бер сүз дә юк.

Бу мәктүбдән соң мәсьәлә тагын бераз үзгәрде. Бик күп уңгайсызлыклар бар. Берсе – мин заграничный паспортымның хөкеме югала. Яңадан алу бик авыр мәсьәлә. Бирмәү ихтималлары да бик якын. Бу – бер. Икенчедән, солдатка каралырга кирәк. Солдатка алулары да бик якын, ул вакытда бөтен план пыран-заран килгән була. Шуның өчен боларның берсе дә ярамый. Фәкать качып керергә, аның өчен минем кулымда нинди булса да паспорт булырга кирәк. Миңа Харбиндан җибәрергә вәгъдә иткән булсалар да, ул да килмәгән. Качып-посып чыгарга маташырга, ләкин бу вакытда тотсалар, зур күңелсезлекләр булу ихтималы бар. Ләкин мондый вакытда куркып торсаң, бер нәрсә чыкмый. Аллага тапшырырга, хәрәкәт итәргә...

*Текстны басмага әзерләде:*
***Гарипова Ләйлә Шамил кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

---

[1] Фуад Туктаров – Фуад Фәссах улы Туктаров (1880–1938) – журналист, язучы, сәясәтче.

[2] Солтанбәк – Солтанбәк Мәмлиев, Петроград Эшче-солдат депутатлар советының әгъзасы.